Республика Татарстан
СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422071, Республика Татарстан,
с.Кильдебяк, ул Кооперативная, д. 20 а
тел.45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20 а йорт
тел. 45-5-50

e-mail: kilb.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.02.2018 №3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 28.11.2006 ел №25 “ Килдебәк авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар турында нигезләмәне раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 31.01.2018 ел 02-08-02-12-2018 ризасызлыгы нигезендә Килдебәк авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Килдебәк авыл җирлеге Советының 28.11.2006 ел №25 карары белән расланган “Халык алдында тыңлаулар турында нигезләмәнең 3.1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Халык алдында тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарыла:

- муниципаль берәмлек уставына РФ Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарны, РФ субъектлары законнары яки конституциясен (уставын)төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертү очрагыннан башка, муниципаль берәмлек уставының проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив-хокукый акт проекты, бирелгән уставны әлеге норматив-хокукый актларга туры китерү максатында;
- җирле бюджетһәм аның үтәлеше турында хисап проекты;
- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш проекты;
- гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлектә яшәүче халыкның рөхсәтен тавыш бирү юлы белән яисә халык җыенында алу таләп ителгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында сораулар;
- генераль план проектлары буенча, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре проекты, биләмәне планлаштыру проектлары, биләмәне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары; күрсәтелгән, расланган документларга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар; шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объектын куллануга рөхсәт бирү турында карарлар проекты; рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары чигеннән читкә чыгу рөхсәтен бирү, капиталь төзелеш объектларын яңадан үзгәртеп төзү карарлары проекты; җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре

булмаган очракта җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларын бер рөхсәт ителгән файдалану төреннән икенчесенә күчерү мәсьәләсе буенча халык алдында тыңлаулар үткәрелә; оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнчалыкның нигезләмәләрен һәм җирлекнең аерым муниципаль норматив-хокукый актларын исәпкә алып билгеләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.
3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Загидуллин